Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

# REVIEW OF THE GABDULLA TUKAY ENCYCLOPEDIA ([EDITOR-IN-CHIEF Z. Z. RAMIEV]. KAZAN: G. IBRAGIMOV LANGUAGE, LITERATURE AND ART INSTITUTE, 2016. 861 P., ILLUSTRATED)

**Tagir Gilazov,**
Kazan Federal University,
18 Kremlevskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
tgilazov@bk.ru.

The present review sheds light upon the history of Gabdulla Tukay Encyclopedia. The Encyclopedia is the first published work of this kind devoted to the famous Tatar poet. Besides providing brief information about researchers and intellectuals, who took part in its compilation, the review describes the structure of the edition, the life and career of the poet, his cultural oeuvre, which covers literal, esthetic, social and philosophical aspects of the poet's work, given in thematic articles. At the same time with reading the articles, the reader can discover rich illustrative material and a high quality of printing. The Gabdulla Tukay Encyclopedia is appreciated as a great historical event, being of great value to further fundamental work in the area of Tatar Humanitarian Science.

**Key words**: Tukay Studies, Tatar poetry, literary criticism, textology, thematic diversity, structure, principle, cultural life.

Being a classic poet of his nation, Gabdulla Tukay fueled the spread of national literature traditions throughout Eastern and Arabian cultures and brought national poetry out onto the world stage. His creative works have become the core of Tatar literature and the history of social and philosophical thought. Despite political and social controversies of his century, the genius of the early 20$^{th}$ century, G. Tukay, and his works remained the focus of academic research. Gabdulla Tukay Studies continued to develop and expand throughout the years, overcoming hardships and withstanding the test of time, they went on exploring every stage of his literary oeuvre, theoretical views on his works, discoveries of the poet's creative work, etc. In 1960–1970, researchers found new terms to describe their investigations: "Tukay Studies" and "Tukay in Scientific Research". They aimed to form a new trend, an independent branch of Tatar literary science defined as "Tukay Studies". T. Nabiullin wrote: "The research devoted to the study of Gabdulla Tukay made great advances in 1960–1970. Owing to the selfless work of such scientists as M. Gainullin, G. Khalit, R. Nafigov, Kh. Gusman, I. Nurullin and R. Bashkirov, Tukay Studies made good progress and rapidly developed. These traditions were also kept up by

M. Mahdeev, N. Yuziev, N. Lisov, F. Yakhin" [Galiullin, 2002, p. 28].

In 1978, the idea of compiling a personal encyclopedia of Gabdulla Tukay was raised for the first time. The foundation was laid by the systematized achievements in studying Tukay's works and his spiritual heritage, which enhanced progress of the national culture and promoted research into the poet's oeuvre and his literary activities. This issue was covered in mass media by such researchers as N. Yuziev and A. Karimullin.

Taking the encyclopedia of the great Russian poet M. Y. Lermontov as a model, N. Yuziev created the conception and structure of this edition in 1993–1996. Tatar scholars N. Yuziev, M. Akhmetzyanov, R. Ganeeva, Z. Ramiev and F. Yakhin formed thematic teams and prepared articles and scientific papers. Soon they submitted the manuscript the "Tukay Encyclopedia Glossary" for publication and it was published in 1998.

Due to the healing wind of change of the late 20th century, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan founded the Department of Humanities. During one of its opening sessions, the members of the Academy discussed the issue of compiling the Tukay Encyclopedia. Mansur Khasanov and his colleagues analyzed the accumulated knowledge on the subject [Ramiev, 2014, p. 106], they admitted the need for its creation and started working in this direction. In 1996, Z. Ramiev was put in charge of this project. He employed new principles and methods for validating and evaluating the poet's literary heritage. To fully and extensively reflect Tukay's personality and his oeuvre, the researchers analyzed his activity in the beginning of the 20th century both in socio-political and cultural contexts. In addition, the Encyclopedia was supposed to include information about the poet's internal and external literary connections, traditions and transitivity of his works, the topics and the image of the poet in science and culture. As a result, the main sections and the whole content of the Encyclopedia fell into their places.

The process of compilation was hard scientific work, demanding accuracy, intelligence, power of observation and energy. Moreover, a lack of experience in this area meant a greater amount of time spent on this novel project. However, "to familiarize the literary and scientific community, as well as the readers, with the process of the Encyclopedia compilation, T. N. Galiullin, R. K. Ganieva, Kh. Yu. Minnegulov, Z. Z. Ramiev, R. F. Kharrasova, N. Sh. Khisamov et al. published articles in newspapers, magazine, journals and books. Dozens of articles on the creation of the Encyclopedia appeared in the sections of such journals as 'Megerif" ("Education"), "Beznen Miras ("Our Heritage"), informing the readers of the results of their work". [Editor-in-Chief, p. 8]. Being the head of the group of scientists, who studied Tukay, Z. Z. Ramiev informed the general public of the process of compiling the Encyclopedia, the difficulties they experienced and the results of this work at different events dedicated to the poet.

The "Gabdulla Tukay Encyclopedia" was published in 2016. The Encyclopedia opens with a preface, written by the editor-in-chief Z. Z. Ramiev. The President of the Republic of Tatarstan, R. N. Minnikhanov, appreciated this fundamental work in his welcome address "Dear readers!". He emphasized the importance of this work for the spiritual life and culture of the nation: "In 2016, we celebrate the 130th anniversary of the outstanding thinker and poet. <…> I consider the publication of this first personal encyclopedia in the Tatar language, of this great work the "Gabdulla Tukay Encyclopedia", to be a memorable and remarkable event in the cultural life of Tatarstan. When the readers get this Encyclopedia, they will be able to realize again that today the poet is still our ideal. I believe, the poet's literary gift, his social and political views, his verses will never leave anyone indifferent" [Minnekhanov, p. 3].

The articles of the Gabdulla Tukay Encyclopedia have been written by the scientists of G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Institute of Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, researchers of Kazan universities and institutes and significant figures of literature and art.

The introduction to the encyclopedia aims to provide brief information about the edition and how to use it, therefore, there are such useful articles as "How to use the Gabdulla Tukay Encyclopedia", "Basic shortenings in the Gabdulla Tukay Encyclopedia", "Abbreviations". "The Content of Gabdulla Tukay's Works", "The Authors of Articles in the Gabdulla Tukay Encyclopedia". The reader can find such useful appendices as "The winners of the State prize of the Republic of Tatarstan named after Gabdulla Tukay" and "References to literary works on the life and works of Gabdulla Tukay" at the end of the publication.

According to the general concept of the encyclopedia, 2358 articles have been divided into eight thematic units. The first unit analyses Gabdulla

Tukay's creative activity and his best works focused on different genres of literature. This unit includes the poet's works, journalistic and satirical articles, scientific publications, which have not been published before for ideological reasons, as well as research manuscripts. The article provides scientific interpretations and describes the features of the poet's creative thinking, the themes and motifs of his works, their genre, literary approaches, the poet's discoveries, which led him to national poetry and a profound analysis of the structure of his lyrical works. It also contains information on the history of works and their publication (texts). Here we can find a few works, which after a careful analysis, were attributed to the poet.

Having established a scientific basis of the main concept and regulations, the Encyclopedia provides a scientific interpretation of Gabdulla Tukay's heritage. The second unit is devoted to the literary concepts and terms connected with Gabdulla Tukay's creative activity and the challenges that this area has, which required deep concentration of thought and a flow of new ideas. It is well-known, that the achievements in Tukay Studies have had a great impact on the development of Tatar literature, as T. Gilayzov's research has proved: "The study of Tukay is conducted in line with literary scientific research, it forms the core of literature. It has influenced the development of Tatar literature." In particular, the challenges of moving from educational realism to critical realism were overcome due to Tukay's works. Romanticism, as a form of the creative image of life, got its rightful place in the national literature owing to the study of Tukay's works. [Gilyazov, 2005, p. 78]. The articles of this unit are dedicated to the artistic originality of the poet's oeuvre, literary trends and literary creative movements, ideals, genres, artistic approaches, our nation and national features, traditions and novelties, etc.

A historical and cultural picture of that time is represented through the relationships of Gabdulla Tukay's life and works with people from different social groups, the famous people who played a significant role in shaping him as a poet, his creative friends and like-minded people, his grandparents, mother, friends and close people, who gave him the warmth of their soul. The third unit contains the list of authors of the articles, based on Tukay's autobiographical work "What I Remember" (1909), the poet's memories and personal letters. All these depict the poet's moral and spiritual world, introduce the readers to Tukay's surroundings and environment.

The fourth unit contains articles, analyzing connections of Tukay's activities with the context of this millennium's Tatar literature, Tatar medieval literature, new century's national literature, as well as the issue of maintaining the poet's traditions in Tatar poetry and in modern literature. "Tukay is the basis of the 20$^{th}$ century poetry, the gem of the nation; every poet draws inspiration and perspective from this creative spring." [Galiullin, 2002, p. 27] The new independent trend emerged based on the theme of Tukay and the poet's image in literary-aesthetic and social-philosophical aspects. It determined the development vector of Tatar literature. "Tukay's poetry enhances the novelty of the 20$^{th}$ century literary-aesthetic thought, the continuity of literary traditions and their development, it enables us to verify the shades of meaning, laying the foundation for national literature and maintaining its values [Yusupova, p.105]. Therefore, this unit contains articles devoted to works about poet's life, his spiritual heritage, personality, identity, opinions and traditions. The unit also presents articles about Tukay from newspapers and journals, describing his multi-faceted work for Tatar social and political journalism with the aim of broadening the reader's horizons by providing information about the poet's life and activity.

The fifth unit of the Encyclopedia consists of articles about the connection of Tukay's spiritual heritage with his literary and cultural oeuvre. It is about the Tukay, who renewed both our nation's spiritual power and its literary traditions, and presented Tatar literature on the world arena. It is well-known, that G. Tukay's poems and verses, with their deep philosophical meaning and meaning of life, were translated into Russian and Arabian: "In 1908–1913, Tukay linked his own creations with Russian and world literature, translating them into Russian and familiarizing the readers with world literature and culture. Due to these translations, we can learn that he was an admirer of Shakespeare, Byron, Schiller, Goethe and Heine" (word for word trans. – *T. G.*) [Galiullin, Khabutdinova, p. 55]. This unit studies the connections of Tukay and his works with Turkic people's famous writers and literature, his contacts with the people from the Volga region.

Tykay's life, his personality and creative activity influenced all spheres of Tatar culture of the 20$^{th}$ century. He always believed in the development and prosperity of Tatar culture, and supported any idea contributing to this course. Thus, in the sixth unit we find different articles, papers and in-

formation about the influence of Tukay on Tatar culture in the 20th century as well as materials on such topics as Tukay and music, Tukay and theatre, Tukay and fine arts. This unit is of special interest owing to useful and rich factual materials, mass media publications, and monographs, which escaped the attention of the reader. In addition, the unit provides new interesting and concise information.

Tukay lived a very brief life. It was closely connected with social, spiritual and cultural dramatic changes in the country and in the world, with people and the whole Tatar nation. Therefore, his life abounds in memories and surprisingly notable and exciting events. The poet's biography is associated with different parts of Russia, as Tukay used his short life (as a prophet he felt his lifespan would be short) for useful activities, travelling, getting to know the world and living a full life. The seventh unit provides information about places related to Tukay's life and his creative activity. Here we read about the poet's reflections and thoughts on literal topography, which is found in his works. The articles have data on "such cities, towns and villages as Turkey, Uralsk, Moscow, Bolgar, Elabuga, Kushlavich, and Kyrlay: the hostels where the poet lived or stayed for a while, the madrasah, where he or his acquaintance studied, the museums in Kazan, Arsk and Uralsk" [Editor-in-chief, p. 8].

Researchers Dzh. Validi, F. Burnash, G. Nigmati, Ya. Agishev, G. Khalit, I. Nurullin, R. Nafigov and others devoted their lives to the study of the great poet's life and activities, making great contributions to Tulkay Studies. Moreover, the study of Tukay has been enriched by scientific thoughts and recollections of famous people, who have enhanced the development of Tatar literature. The eighth unit presents articles on their works related to Tukay. There are also materials on authors, whose research monographs and theses are dedicated to Tukay and the scholars' special glance-assessment of public opinion. The Encyclopedia gives various names and pseudonyms of the poet, found in his publications and works.

The Encyclopedia, as an academic edition of Tukay Studies, makes it possible to further develop novel research into Tatar literature. While the Encyclopedia was compiled, it was proved that literary connections between Turkic peoples established in ancient and medieval times were interrupted after the disintegration of the USSR (1991). Closer cooperation with literatures and cultures of the peoples from the Volga region is strongly recommended. An example of close collaboration is the edition of "Words about Tukay", published on the 100th anniversary of Gabdulla Tukay (1986), where thirty eight famous Volga region scientists, eminent writers and well-known poets presented their research papers, articles on Tukay and reviews of Tukay's oeuvre. The experience of compiling and publishing the Encyclopedia will be of use in the compilation of encyclopedias of Gayaz Iskhaki, G. Ibragimov and other authors.

**References**

*Bash redactor. Ukuchylar igtibaryna.* (2016). [The Editor-in-Chief. To Readers]. Gabdulla Tukay. Encyclopedia. Bash. muh. Z. Z. Ramiev. Pp. 6–8. Kazan, G. Ibragimov isem. Tel, edebiyat hem sengat instituty. (In Tatar)

*Gabdulla Tukay eserlere: suzlek-beleshmelek.* (2012). [The Works of Gabdulla Tukay: Companion Book]. Tuz. hem keresh suz avt. Z. Ramiev; fen. muh Z. Ramiev, Z. Sheykhelislamov. 480 p. Kazan, Tatar.kit.neshr. (In Tatar)

*Gabdulla Tukay. Encyclopedic suzlek-beleshme (mekaleler hem beleshmeler isemlege).* (1998). [Gabdulla Tukay. Encyclopedic Companion Book (Reference List of Articles)]. Tuz.: N. Yuziev, R. Ganieva, M. Ehmetzhanov, Z. Ramiev, F. Yahin. 78 p. Kazan. (In Tatar)

*Gabdulla Tukay. Encyclopedia.* (2016). [Gabdulla Tukay. Encyclopedia]. Bash. muh. Z. Z. Ramiev. 864 p. Kazan: G. Ibrahimov isem. Tel, edebiyat hem sengat instituty. (In Tatar)

Galiullin, T. N. (2002). *Tukay shigyrleren yanadan ukyganda* [Rereading Tukay's Poems]. Shigriyat baskychlary: Edebi tenkyjt mekalelere. Pp. 28–46. Kazan: Megarif. (In Tatar)

Galiullin, T. N. (2002). *Shigriyat baskychlary: Edebi tenkyjt mekalelere* [Stage Poetry: Literary-Critical Articles]. Pp. 28–46. Kazan, Megarif. (In Tatar)

Galiullin, T. N., Khabutdinova, M. M. (2014). *Zapadnoevropejskaja klassika v perelozheniyah G. Tukaya* [West-Eastern Classic in Tukay's Versification]. TATARICA. No.1 (2). Pp. 55–61. Kazan, Kazan Federal University publishing house. (In Russian)

Ganieva, R. K. (2002). *Shagyrnen rukhi dunyasy ("Gabdulla Tukay" encyclopedic suzlek-beleshmesene ezerlengen materiallardan)* [Spiritual World of the Poet (materials for "Gabdulla Tukay" encyclopedic companion book)]. 112 p. Kazan, TaRIKH. (In Tatar)

Gyilazhev, T. Sh. (2005). *Edebi miras: tarikh hem zaman* [Literary Heritage: History and Epoch]. 206 p. Kazan, Tatar. kit. neshr. (In Tatar)

Khisamov, N. Sh. (2003). Tukayny tushenu julynda ("Gabdulla Tukai" encyclopedic suzlek-beleshmesene ezerlengen materiallardan) [On the Way to Tukay (Materials for Gabdulla Tukay Encyclopaedic Companion Book]. 79 p. Kazan, TARIKH. (In Tatar)

Khisamov, N. Sh. (2003). Tukayny tushenu julynda ("Gabdulla Tukai" encyclopedic suzlek-beleshmesene

ezerlengen materiallardan) [On the Way to Tukay (Materials for Gabdulla Tukay Encyclopaedic Companion Book]. 79 p. Kazan, TARIKH. (In Tatar)

*Lermontovskaja encyclopedia.* (1981). [The Lermontov Encyclopedia]. AN SSSR. Int rus. lit. (Pushkin. Dom); Nauch.-red. sovet izd-va "Sov. Encycl"; gl. red. Manuilov V. A., Redkol.: Andronikov I. L., Bazanov V. G., Bushmin A. S., Vacuro V. E., Zhdanov V. V., Hrapchenko M. B. Moscow, Sov. Jencikl., 746 p. (In Russian)

Minnegulov, Kh. Yu. (2003). *"Tukay encyclopediase" sekhifelerene* [Tukay Encyclopedia]. Gasyrlar unen tynlap... Pp. 143–222. Kazan, Megarif. (In Tatar)

Ramiev, Z. Z. (2008). *O hode raboty nad tukaevskoj encyclopediey* [On Compiling the Tukay Encyclopedia]. Tekstologiya tatarskoj literatury XX veka. Pp. 144–149. Kazan, Alma-Lit. (In Russian)

Ramiev, Z. Z. (2014). *Tukay encyclopedia se kaychan bulyr?* [When Do We Have the Tukay Encyclopedia?]. Edebiyatchy-tekstolog yazmalary (1990–1913). Pp. 101–108. Kazan, Ikhlas. (In Tatar)

*Slovo o Tukae. Pisateli i uchenye o tatarskom narodnom poete.* (1986). [A Word about Tukay. Writers and Scholars about the Tatar National Poet]. Sostavlenie i kommentarii F. M. Zulkarnaeva. 43 p. Kazan, Tatknigoizdat. (In Russian)

Yusupova, N. M. (2014). *XX gasyr Tatar pojeziyasende Tukay obrazy: edebi-jestetik hem iңtimagyj-felsefi geudeleneshe* [The Image of Tukay Poetry of the 20th Century: Artistic-Aesthetic and Social-Philosophical Images]. TATARICA. No. 1 (2). Pp. 98–106. Kazan, Kazan Federal University Publishing House. (In Tatar)

---

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ. ЭНЦИКЛОПЕДИЯ ([БАШ МӨХ. З. З. РӘМИЕВ]. КАЗАН: Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМ. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ, 2016. 861 Б., ИЛЛ. Б-Н) БАСМАСЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Таһир Шәмсегали улы Гыйлаҗев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
tgilazov@bk.ru.

Бәяләмәдә татар әдәбият фәнендә беренче мәртәбә нәшер ителгән татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның персональ (шәхси) энциклопедиясен төзү тарихы бәян ителә. Фундаменталь басманы чыгаруга тартылган төрле катлам галимнәре, зыялылары белән таныштырудан тыш, фәнни хезмәтнең төзелеше, шагыйрьнең тормышы юлын һәм рухи мирасын әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-фәлсәфи яссылыкта ачкан мәкаләләрне үз эченә алган тематик юнәлешләр хакында белешмә бирелә. Язмаларның эчтәлеген ачуга хезмәт иткән иллюстрацияләрнең байлыгы, басманың югары полиграфик эшләнеше хәбәр ителә. Зур тарихи-мәдәни вакыйга буларак бәяләнгән энциклопедик басманың татар гуманитар фәннәрендә гыйльми эзләнүләрнең яңа юнәлешләрен билгеләве ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** Тукай гыйльмияте, татар поэзиясе, әдәбият фәне, текстология, тематик юнәлешләр, төзелеш, принцип, мәдәни тормыш.

Татар әдәбият фәненең һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихының үзәгендә милли сүз сәнгатенең классик шагыйре, элгәрге әдәби традицияләрне шәрык һәм гареб мәдәниятләре казанышларында иҗади үстереп, милли шигъриятне дөнья киңлекләренә чыгарган Габдулла Тукай иҗаты тора. XX гасыр башы даһие Тукайның күпкырлы эшчәнлеге, чорның каршылыклы сәяси-җәмгыяви җилләренә карамыйча, тикшерелүен һәм бәяләнүен дәвам итә. Шагыйрь мирасын гыйльми күзаллаудагы һәр этапта, аңа кадәрге теоретик гомумиләштерүләр, табышлар иҗади үзләштерелеп, заман һәм тормыш сынавын үткән, фәнни кыйммәтен югалтмаган сыйфатларга таянып, Тукай фәне тирәнәя һәм киңәя бара. 1960–1970 елларда шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләр «Тукай фәне», «Тукай турындагы фән» терминнарына мөрәҗәгать итеп, әдәбият фәнендә мөстәкыйль тармак буларак Тукай гыйльмияте формалашу хакында фикер йөртә башлыйлар: «Тукай турындагы фән алтмышынчы-җитмешенче елларда җитди казанышларга ирешә. М. Гайнуллин, Г. Халит, Р. Нәфыйгов, Х. Госман, И. Нуруллин, Р. Башкуров кебек галимнәрнең фидакарьлеге нәтиҗәсендә Тукай фәне бик нык алга китте. Бу йола күпмедер күләмдә М. Мәһдиев, Н. Юзиев, Н. Лаисов, Ф. Яхиннар тарафыннан үстерелде»

[Галиуллин, 2002, б. 26], – дип яза Т. Галиуллин.

Тукай иҗатын өйрәнүдә ирешкән казанышларны системалаштырып, татар халкы алгарышының һәм мәдәни үсешенең этәргече булган шагыйрьнең рухи мирасын татар җәмәгатьчелегенә җиткерү һәм исемен мәңгеләштерү максатыннан, аның шәхси энциклопедиясен төзү мәсьәләсе 1978 елда беренче мәртәбә көн тәртибенә куелып, әдәбият галимнәре Н. Юзиев һәм Ә. Кәримуллин тарафыннан матбугат битләрендә яктыртыла. Рус әдәбиятының бөек шагыйре М. Ю. Лермонтов энциклопедиясе үрнәк-өлге итеп алынып, 1993–1996 елларда Н. Юзиев бу басманың гомуми концепциясен һәм структурасын эшли. Татар галимнәре Н. Юзиев, М. Әхмәтҗанов, Р. Ганиева, З. Рәмиев, Ф. Яхин тарафыннан энциклопедиянең тематик төркемнәре һәм аларда урын алачак мәкаләләр исемлеге төзелеп, аның кульъязма хокукындагы «Тукай энциклопедиясенең лөгатьлелеге» (1998) нәшер ителә. XX гасыр ахыры кискен үзгәрешләрнең шифалы җилләре нәтиҗәсендә оешкан «Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең гуманитар фәннәр бүлеменең киңәйтелгән утырышында ул [энциклопедия төзү мәсьәләсе. – *Т. Г.*] Мансур Хәсәнов катнашында җентекле тикшерү узып» [Рәмиев, 2014, б. 106 ] хуплана һәм әлеге җаваплы эшкә керешелә. 1996 елда бу проект белән җитәкчелек З. Рәмиевкә йөкләнә. Әдәби мирасны һәм әдәбиятны тикшерү һәм бәяләүнең яңа принциплары һәм методикасы бу эшчәнлеккә үзгәрешләр кертә. Тукай шәхесен һәм мирасын тулырак һәм киңрәк чагылдыру максатыннан, аны XX гасыр башындагы иҗтимагый-сәяси вәзгыять һәм мәдәният контекстында тикшерү бурычы калкытып куела. Аннан тыш эчке һәм тышкы әдәби бәйләнешләр, иҗатта традицияләр һәм күчемлелек, шагыйрь темасының һәм образының фәндә һәм сәнгатьтә чагылышы кебек мәсьәләләргә игътибар энциклопедия төзүгә яңалыклар кертә. Нәтиҗәдә басманың төп бүлекләре һәм аларның эчтәлеге тагын да ачыклана төшә.

Катлаулы фәнни хезмәтне төзү эше, зур акыл көче һәм фикри егәрлек соралу һәм бу тармакта тәҗрибәнең дә аз булуы сәбәпле, вакыт таләп итә. Дөрес, «Әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелекне, гомумән, укучыларны ГТЭ төзү барышы белән таныштырып тору максатында Т. Н. Галиуллин, Р. К. Ганиева, Х. Й. Миңнегулов, З. З. Рәмиев, Р. Ф. Харрасова, Н. Ш. Хисамов һ. б. авторлар үзләренең мәкаләләрен вакытлы матбугат битләрендә урнаштырды, китап-җыентыкларда бастырды. Энциклопедиягә әзерләнгән дистәләгән мәкалә „Мәгариф“, „Безнең мирас“ журналларында ачылган махсус сәхифәләрдә укучылар игътибарына тәкъдим ителде» [Баш редактор, б. 8]. Тукайчы галимнәр төркеме җитәкчесе З. З. Рәмиев шагыйрьгә багышланган төрле чараларда энциклопедия эшенең нәтиҗәләре һәм кайбер кыенлыклары хакындагы фикерләрен җәмәгатьчелеккә даими җиткерде.

2016 елда басылып чыккан «Габдулла Тукай энциклопедиясе» баш редактор З. З. Рәмиевнең «Укучылар игътибарына» дип исемләнгән сүз башы белән ачыла. Татарстан Республикасының Президенты Р. Н. Миңнехановның әлеге фундаменталь хезмәттәге «Хөрмәтле китап укучылар!» дигән мөрәҗәгатендә энциклопедиянең татар халкы рухи һәм мәдәни тормышындагы кыйммәте югары бәяләнә: «2016 елда без татар мәдәниятенең күренекле иҗатчысы һәм фикер иясе Габдулла Тукайның 130 еллыгын билгеләп үтәбез. <...> Әлеге күренекле вакыйга уңаеннан татар телендә беренче шәхси энциклопедия – Тукай энциклопедиясе басылып чыгу Татарстанның мәдәни тормышында истә калырлык бер вакыйга булыр дип ышанам. Китапны кулына алган һәр кеше шагыйрьнең бүген дә әхлакый идеал булуын тагын бер кат ачар. Аның үзенчәлекле әдәби сәләте, иҗтимагый-сәяси карашлары, иң нечкә кылларын тибрәткән шигырьләре беркемне дә битараф калдырмас дип уйлыйм» [Миңнеханов, б. 3].

Габдулла Тукай энциклопедиясендәге мәкаләләр ТР ФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты фәнни хезмәткәрләре, Казан шәһәренең югары уку йортлары җәмәгатьчелеге, әдәбият һәм сәнгать әһелләре тарафыннан язылган.

Хезмәтнең баш өлешендә, укучыны хезмәт белән таныштыру һәм аннан файдалануны җиңеләйтү максатыннан, «Тукай энциклопедиясеннән ничек файдаланырга», «Тукай энциклопедиясендә кулланылган төп кыскартулар», «Аббревиатуралар», «Габдулла Тукай басмаларының энциклопедик бирелеше», «Тукай энциклопедиясе мәкаләләренең авторлары», ә ахырда «Татарстан Республикасының

Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреатлары», «Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында мөһим әдәбият» кушымталары урын алган.

Басмага әзерләнгән 2358 мәкалә, энциклопедиянең гомуми концепциясенә нигезләнеп, сигез тематик бүлеккә урнаштырылган. Беренче тематик юнәлештә төрле жанрларның югары үрнәкләрен биргән Габдулла Тукайның бай һәм киңкырлы әдәби иҗаты анализлана. Бу бүлеккә аның әдәби әсәрләре, публицистик һәм сатирик мәкаләләре, идеологик басым астында фәнни басмаларына кертелмәгән текстлары, басылмыйча калган кульъязмалары фәнни яктан шәрехләнеп, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге, тема-мотивы, жанр хасияте, әдәби алымнар, шагыйрьнең милли шигъриятькә алып килгән табышлары, лирик әсәрләрнең төзелеш үзенчәлекләре бәяләнгән мәкаләләр кертелгән. Әсәрнең (текстның) басылу һәм язылу тарихлары хакында мәгълүмат бирелгән; бүлектәге шагыйрьнеке булу ихтималы булган әсәрләр дә шушы форматта тикшерелгән.

Гыйльми-нәзари фикернең терәк төшенчәләренә һәм кагыйдәләренә нигезләнгәндә генә, Габдулла Тукайның мирасын фәнни югарылыкта һәм тулы яктырту мөмкин. Икенче бүлектә фикри-гаклый тирәнлекне таләп иткән Тукай иҗаты белән бәйләнешле әдәбият белеме терминнары һәм проблемаларына багышланган язмалар урын ала. Билгеле булганча, Тукай турындагы гыйльмият ирешкән казанышлар әдәбият фәне үсешенә этәргеч ясый. Әлеге бәйләнеш Т. Ш. Гыйлаҗев эзләнүләрендә ассызыклана: «Тукай фәне әдәбият белеме белән бергә атлый: хәтта аның үзеген тәшкил итә. Шулай ук аның үсешенә дә үзеннән мәгълүм өлеш кертә. Аерым алганда, әдәбиятның мәгърифәтчелек реализмыннан тәнкыйди реализмга күчешенең катгыйлыгын раслаган фикер Тукай иҗаты мисалында кире кагыла, йә булмаса тормышны сәнгатьчә гәүдәләндерүнең бер формасы булган романтизм, аның милли әдәбиятта яшәү хокукы да Тукайны өйрәнү юлында уңай хәл ителә» [Гыйлаҗев, 2005, б. 78]. Мәкаләләрдә шагыйрь сәнгатьчә фикерләвенең хосусиятләре, иҗат юнәлешләре һәм әдәби агымнар, идеал, жанр, сәнгати алымнар, халыкчанлык, миллилек, традицияләр һәм яңачалык һ. б. лар тикшерелә.

Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты, төрле социаль төркем вәкилләре, аның шагыйрь буларак формалашуында зур роль уйнаган күренекле шәхесләр, иҗади дуслары, мәсләктәшләре һәм дә аңа күңел җылысы һәм яшәү көче биргән ата-бабалары, әнисе, туганнары, кардәшләре, якыннары белән тыгыз бәйләнеш хасил итеп, шул чорның тарихи-мәдәни картинасын тудыра. Өченче бүлектә мәкаләләр язылган шәхесләрнең исемлеге Тукайның «Исемдә калганнар» (1909) автобиографик әсәренә, истәлек-хатирәләргә, шагыйрьнең шәхси хатларына таянып тупланган. Алар, шагыйрьне рухи-әхлакый яссылыкта ачып, Тукай даирәсе һәм мохите белән укучыларны таныштыралар.

Дүртенче бүлектә Тукай иҗатын меңъеллык татар әдәбияты, аеруча, Урта гасыр татар әдәбияты, Яңа чор милли сүз сәнгате белән эчке бәйләнешләр контекстында анализлаган, татар поэзиясендә шагыйрь традицияләре һәм аларның күчемлелеге мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләргә урын бирелә. «Тукай – XX гасыр татар поэзиясенең нигезе, алтын баганасы, һәр шагыйрь бу иҗат чишмәсеннән үзенең сәләт көченә, юнәлешенә карап илһам нуры ала» [Галиуллин, 2002, б. 27], – дип яза Т. Галиуллин. Тукай темасын һәм шагыйрь образын әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-фәлсәфи яссылыкта гәүдәләндерү татар әдәбиятында мөстәкыйль юнәлеш барлыкка китерә һәм аның үсеш үзенчәлекләрен билгели: «Тукай турындагы шигърият XX гасыр әдәби-эстетик фикерендә барган яңарышларны тагын бер кат шәрехләп бара, әдәби традицияләрне дәвам ителешен, үстерелешен, мәгънәви баетылышын дәлилли һәм сүз сәнгатенең милли нигезләрне, кыйммәтләрне югалтмавы хакында сөйли» [Йосыпова, б. 105]. Шул сәбәпле шагыйрь тормышын, рухи мирасын, шәхесен, традицияләрен, фикер-карашларын сурәтләгән әсәрләр турындагы мәкаләләр дә әлеге тематик юнәлештә туплап бирелә. Тукайның татар матбугаты белән күпкырлы бәйләнешен бәяләү һәм укучыларның шагыйрь турында гыйльми күзаллауларын киңәйтү максатыннан, газета һәм журналлар хакында гомуми белешмә бирелгән мәкаләләр дә бу бүлектә урын ала.

Халкыбызның электән килгән рухи егәрлеген һәм әдәби традицияләрен яңартып, милли сүз сәнгатен дөнья киңлекләренә чыгарган Тукайның рухи мирасын тышкы әдәби-мәдәни бәйләнешләр контекстында анализлаган мәкаләләр энциклопедик басманың бишенче бүлегенә карый. Мәгълүм булганча, Г. Тукай иҗатының һәр чорында, тормышка һәм яшәү гаме, мәгънәсе кебек фәлсәфи

мәсьәләләргә мөнәсәбәтеннән чыгып, атаклы рус һәм аның аша гареб сүз мастерларының әсәрләрен тәрҗемә итә: «1908–1913 елларда Тукай, үз иҗади “мин”енең күңел дөньясында рус һәм дөнья мәдәнияте казанышларын эретеп, татар укучыларын дөнья әдәбияты әсәрләре белән таныта. Шагыйрь тәрҗемәләреннән Шекспир, Байрон, Шиллер, Гете һәм Гейне аның кумирлары булуы күренә» (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Т. Г.)* [Галиуллин, Хабутдинова, б. 55]. Бу бүлектәге язмаларда Тукайны үз шигъри остазлары санаган тугандаш-төрки халыкларның күренекле язучылары, әдәбиятлары белән мөнәсәбәт, Идел буе халыкларының сүз сәнгатьләре белән контактлар гыйльми күзаллана.

Язмаларында татар мәдәниятенең яңарышына һәм күтәрелешенә хезмәт иткән һәр файдалы гамәлгә уңай мөнәсәбәт белдереп, хуплап чыккан Тукай тормышы, шәхесе һәм иҗатының образлы гәүдәләнеше XX гасырда татар сәнгатендәге төрле тармакларның алгарышын тәэмин итте. Шул рәвешле әлеге темага багышланган мәкаләләр һәм белешмәләр Тукай музыкада, театрда, рәсем сәнгатендә дигән юнәлешләргә берләштерелеп, алтынчы бүлеккә тупланды. Мәкаләләр фактик материалның байлыгы, матбугат битләрендә, монографияләрдә ассызыкланып та, укучы игътибарыннан читтә калган, йә булмаса бөтенләй яңа мәгълүматларны кыска һәм кызыклы формада тәкъдим итүләре белән аерылып тора.

Ил, дөнья күләмендә генә түгел, татар халкының кискен иҗтимагый-рухи һәм мәдәни үзгәрешләр чорына туры килгән Тукайның кыска гомере төрле вакыйга-хәлләргә, фактларга гаҗәеп бай һәм кызыклы. Берьяктан, язмыш аны Россиянең төрле почмакларына илтеп ташласа, икенче яктан, шагыйрь, үзенә бирелгән гомернең азлыгын пәйгамбәрләрчә сизенгәндәй, актив тормыш белән яши, сәяхәт кылып, дөнья белән таныша. Җиденче тематик юнәлештәге мәкаләләрдә Тукай тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннар хакында белешмә бирелә. Аның иҗатында чагылыш тапкан әдәби топографиягә шагыйрьнең бәя-мөнәсәбәте бәян ителә. Бүлек язмаларында «Тукай әсәрләрендә очраган Төркия, Уральск, Мәскәү, Болгар, Алабуга, Кушлавыч, Кырлай кебек шәһәрләр, авыллар, илләр, үзе яшәгән, йә булмаса тукталып киткән кунакханәләр, үзе һәм танышлары укыган мәдрәсәләр, шулай ук Казандагы, Арча районындагы, Уральскидагы музейлары турында сүз бара» [Баш редактор, б. 8].

Бергасырлык тарихка ия булган Тукай гыйльмиятенең яңарышы һәм үсеше үз акыл-фикри көчләрен шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышлаган тукайчы Җ. Вәлиди, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти, Я. Агишев, Г. Халит, И. Нуруллин, Р. Нәфыйгов һ. б. галимнәр белән тәэмин ителде. Бу катламнан тыш, әдәбият фәне күтәрелешенә һәм мәдәният яңарышына зур өлеш керткән күренекле шәхесләр Тукай турындагы киңкырлы белемнең төрле юнәлешләрен үз гыйльми күзаллаулары белән баетты. Сигезенче бүлектә аларның бары тик Тукайга кагылышлы эшчәнлеге анализланган мәкаләләр урнаштырылган. Шулай ук шагыйрь иҗаты яктыртылган монографик эзләнүләр, диссертацион хезмәтләр авторлары, аның хакында үзенчәлекле караш-бәя әйткән иҗтимагый фикер ияләре хакында да мәгълүмат бирелә. Энциклопедиядә үз әсәрләрен төрле исемнәр, яшерен имзалар астында бастырган Тукайның псевдонимнарына да урын бирелә.

Академик гыйльмиятнең энциклопедик формасы, гуманитар фәннәрнең үсеш дәрәҗәсен билгеләүдән тыш, татар әдәбият белемендә яңа эзләнүләрнең юнәлешләрен ача. Басманы төзү барышында, Советлар берлеге таркалу сәбәпле, борынгы һәм урта гасыр әдәби хәзинәбез уртак булган төрки халыклар белән бәйләнешләрнең өзелүе ачыкланды. Шулай ук Идел буе халыкларының әдәбиятларына һәм мәдәниятләренә игътибарны көчәйтү зарурилыгы күренде. Мәсәлән, Г. Тукайның туына 100 ел тулу уңаеннан дөнья күргән «Слова О Тукае» (1986) җыентыгында рус, тугандаш, Идел буе халыкларыннан 38 күренекле галимнәре һәм язучыларының шагыйрь мирасы әдәби-мәдәни бәйләнешләр контекстында бәяләнгән язмалары урын алган. Басманың бу форматында тупланган тәҗрибә Г. Исхакый, Г. Ибраһимов һ. б. ларның энциклопедияләрен төзү мәсьәләсен дә көн тәртибенә куя.

**Әдәбият**

Баш редактор. Укучылар игътибарына // Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш. мөх. З. З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. Б. 6–8.

Габдулла Тукай әсәрләре: сүзлек-белешмәлек / [төз. һәм кереш сүз авт. З. Рәмиев; фән. мөх-ләре З.

Рәмиев, З. Шәйхелисламов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 480 б.

Габдулла Тукай. Энциклопедик сүзлек-белешмә (мәкаләләр һәм белешмәләр исемлеге) / Төз.: Н. Юзиев, Р. Ганиева, М. Әхмәтҗанов, З. Рәмиев, Ф. Яхин. Казан, 1998. 78 б.

Габдулла Тукай. Энциклопедия / [баш. мөх. З. З. Рәмиев]. Казан: Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016. 864 б.

*Галиуллин Т. Н.* Тукай шигырьләрен яңадан укыганда // Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 28–46.

*Галиуллин Т. Н.* Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Мәгариф, 2002. 231 б.

*Галиуллин Т. Н., Хабутдинова М. М.* Западноевропейская классика в переложениях Г.Тукая // TATARICA. 2014. № 1 (2). С. 55–61.

*Ганиева Р. К.* Шагыйрьнең рухи дөньясы («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2002. 112 б.

*Гыйлаҗев Т. Ш.* Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 206 б.

*Йосыпова Н. М.* XX гасыр татар поэзиясендә Тукай образы: әдәби-эстетик һәм иҗтимагый-фәлсәфи гәүдәләнеше // TATARICA. 2014. №1 (2). Б. 98–106.

*Миңнегулов Х. Й.* «Тукай энциклопедиясе» сәхифәләренә // Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. Б. 143–222.

*Рәмиев З. З.* Тукай энциклопедиясе кайчан булыр? // Әдәбиятчы-текстолог язмалары (1990–1913). Казан: Ихлас, 2014. Б. 101–108.

*Хисамов Н. Ш.* Тукайны төшенү юлында («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2003. 79 б.

Лермонтовская энциклопедия / АН СССР. Ин-т рус. лит. (Пушкин. Дом); Науч.-ред. совет изд-ва «Сов. Энцикл.»; Гл. ред. Мануйлов В. А., Редкол.: Андроников И. Л., Базанов В. Г., Бушмин А. С., Вацуро В. Э., Жданов В. В., Храпченко М. Б. М.: Сов. Энцикл., 1981. 746 с.

*Рамеев З. З.* О ходе работы над тукаевской энциклопедией // Текстология татарской литературы XX века. Казань: Алма-Лит, 2008. С. 144–149.

Слово о Тукае. Писатели и ученые о татарском народном поэте / Составление и комментарии Ф. М. Зулькарнаева. Казань: Таткнигоиздат, 1986. 43 с.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА ЭНЦИКЛОПЕДИЮ «ГАБДУЛЛА ТУКАЙ. ЭНЦИКЛОПЕДИЯ» ([ГЛ. РЕД. З. З. РАМИЕВ]. КАЗАНЬ: ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА ИМ. Г. ИБРАГИМОВА, 2016. 861 Б., ИЛЛ.)

**Тагир Шамсегалиевич Гилазов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
tgilazov@bk.ru.

В рецензии представлена история создания Тукаевской энциклопедии. Дается краткая информация об авторах научных статей, принадлежащих к разным поколениям, рассматривается структура энциклопедии, отличающейся тематическим многообразием материала, где освещается жизненный и творческий путь поэта, эволюция его художественного мира. Отмечается богатство иллюстративного материала, полиграфическое качество издания. Выявлено значение этого фундаментального труда для татарской гуманитарной науки.

**Ключевые слова:** тукаеведение, татарская поэзия, литературоведение, текстология, тематическое многообразие, структура, принцип, культурная жизнь.